ПӘНҖЕШӘМБЕ
4
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 28 (6750)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һәм КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Соңгы сәгатьтә

Безнең гаскәрләр КРАСНЫЙ ЛИМАН, КУЩЕВСКАЯ шәһәрләрен, КУПЯНСК тимер юл узелын һәм ЗОЛОТУХИНО, ВОЗЫ тимер юл станцияләрен алдылар

3 нче февральдә Курскидан төньяктарак районда безнең гаскәрләр ЗОЛОТУХИНО һәм ВОЗЫ тимер юл станцияләрен алдылар һәм, шулай итеп, Курск белән Орел арасындагы тимер юлны кистеләр.

Украинада безнең гаскәрләр КРАСНЫЙ ЛИМАН шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, шулай ук КУПЯНСК тимер юл узелын алдылар.

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, КУЩЕВСКАЯ шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ



«Тамбов колхозчысы» исемле танклар колоннасы фронтка барып җитте. Совет патриотларының саклык акчаларына төзелгән дәһшәтле машиналар сугышка керергә һәм немец бандитларын тар-мар итәргә әзер.

ТАСС фотохроникасы.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ БАРЛЫК ТАРМАКЛАР БУЕНЧА ДА ОТЛИЧНО ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ!

Колхоз авылы, ватан сугышы шартларында, икенче тапкыр буларак хәрби язгы сугышчан төстә каршыларга әзерләнә. Фронтлардагы җиңү тантанасы тылдагы хезмәт күтәренкелеге белән бергә кушылып, илебезнең куәтен тагын да арттырды. Шушы уңай белән җәелеп киткән социалистик ярыш колхоз производствосының барлык тармакларында да ачык чагыла.

Сугыш вакыты үзенең темпларын билгеле. Бер айда эшләнәсе эшләр бер атнада, ә бер атна вакыт таләп итәлә торган эшләр көнендә, сәгатендә үтәлә. Бу совет кешеләренең намусын, ватанга бирелеп эшләүләрен, вакыт белән исәпләшмәүләрен күрсәтә. Республикабызның кайбер колхозлары язгы чәчүгә әзерлекне тәмамлау алдында торалар. Мензә Шөгер районының «Кызыл Шушма» колхозы. Аның чәчүлек орлыгы җитәрлек, авыл хуҗалыгы машиналарына һәм башка инвентарьларга ремонт тәгәлләнгән. Агротехник чаралар үткәрү оешкан төстә бара. Норлат районының «Красный дол» һәм Бондюг районының «Кызыл Илкә» колхозлары да Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә кадәр язгы чәчүгә әзерлекне тәгәлләү өчен барлык тармаклар буенча конкрет йөкләмәләр алып эшкә керештеләр. Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин.

Һәрбер эшне башкарганда үткән көннәргә дә борылып карарга, эштә булган кимчелекләрне вакытында төзәтә барырга, үткәндәге хаталарны кабатламау өчен барлык чараларны күрергә кирәк. 1942 нче елда, кайбер колхозлар чәчүлек орлыкның сыйфаты начар булу сәбәпле чәчү вакытында уңайсыз хәлгә калдылар. Мәсәлән, узган ел Ширәмәт районының Каенлык авылы колхозында 70 гектар бодайның тишелеше начар булу аркасында чәчелгән җирне бозып, яңадан чәчәргә туры килде. Заинский районында да, чәчү мәйданының туфрагы әзерләнеп бетүгә дә карамастан, орлык җитешмәү сәбәпле, чәчү озакка сузылды.

Кайбер районнарда, быел да язгы авыл хуҗалыгы эшләренә әзерлеккә тиешле бәя бирел җиткермиләр. Тельман районы колхозларында һәм совхозларында язгы чәчүгә әзерлекнең барышы турында тикшергәннән соң ВКП(б) Өлкә Комитеты бу мәсьәләдә нык кына кисәтү ясады һәм язгы чәчүгә әзерлекнең барлык тармаклары буенча да күрсәтмәләр бирде. Бурыч—хәзер партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан бирелгән директиваларны үтәү өчен эшне фронттагыча оештырудан гыйбарәт.

Язгы авыл хуҗалыгы эшләрен планлы рәвештә оештыру, әзерлекне бөтен тармаклар буенча да тигез темп белән алып бару—эштә большевистик тәртип урнаштыруны сорый. Кыш ул ял вакыты түгел. Югары иген уңышы алу өчен база әзерләү сыйфатында аннан тулысынча файдаланылырга тиеш.

Чәчүлек орлык чистартылып, коры урыннарга салынып куелган булырга тиеш. Бу эштә орлыкчылык лабораторияләренең дә җитез эшләүләре, орлыкка дип билгеләнгән ашлыкның сыйфатын тикшерүдә колхозларга якыннан торып булышулары кирәк. Яхшы ремонт язгы чәчүнең темпын һәм сыйфатын хәл итәчәк. Шуның өчен авыл хуҗалыгы инвентарен ремонтлауга бөтен көч тупланырга тиеш һәм аны яхшы сыйфатлы итеп тиз тәгәлләү өчен кирәкле барлык чаралар күрелсен. Тарту көчләренең көр һәм сәламәт булуы оборона өчен дә әһәмиятле. Эре мөгезле терлекләрне эшкә өйрәтү тарту көчләрен арттыруның мөһим чарасы икәнен истән чыгармаска кирәк. Кышкы агротехника чаралары да, һичшиксез, үз вакытында үткәрелсен.

Язгы чәчүгә әзерлекнең дә һәм аны үткәрүнең дә уңышын кадрлар хәл итәләр. Авыл хуҗалыгы машиналарын хәрәкәткә китерүче механизатор кадрлар һәм гомумән авыл хуҗалыгы эшләренең барлык төрләре буенча яхшы белгечләр әзерләү, аларны эшкә өйрәтү өчен хәзер иң уңайлы вакыт.

Язгы чәчүгә отлично әзерләнү район оешмаларының, колхоз һәм совхоз җитәкчеләренең оператив эшләүләрен, инициативалы булуларын, сугыш шартларында килеп туган кыенлыклар алдында каушап калмыйча, тапкыр һәм кыю хәрәкәт итүләрен таләп итә. Язгы чәчүгә яхшы әзерлекне тәэмин итү—ул, фронтның таләбен үтәү дигән сүз. Колхозчы массаны үзенең фронттагы батыр улларына, кыю кызларына язгы кыр эшләренә отлично әзерләнү белән җавап бирүгә туплыйк!

МОНГОЛИЯ ХАЛЫК РЕСПУБЛИКАСЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ ХӨРМӘТЕНӘ СССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕНДӘ АШ МӘҖЛЕСЕ

2 нче февральдә, Кремльдә, СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш **И. В. Сталин** фронтка Кызыл Армия сугышчыларына һәм командирларына Монголия халкыннан бүләкләр алып килгән Монголия Халык Республикасы делегациясе хөрмәтенә аш мәҗлесе үткәрде.

Мәҗлестә катнаштылар: делегациянең башлыгы Монголия Халык Республикасының баш министры маршал Чойбалсан, Кече хурал Президиумы Председателе Бумценде, Монголиянең Революцион Халык партиясе Үзәк Комитеты секретаре Сурунжаб, халык ополчениесе баш командующие Мижид, Монголия Халык Республикасының СССР дагы илчесе Самбу, Монголия Халык Республикасы Герое Гонгор һәм делегациянең башка членнары, шулай ук В. М. Молотов, А. И. Микоян, Л. П. Берия, Г. М. Маленков, Маршал Г. К. Жуков, А. Е. Бадаев, В. Г. Деканозов, Ю. М. Каганович, СССР ның Монголия Халык Республикасындагы илчесе И. А. Иванов һәм башкалар.

СССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

„Ватан сугышы партизанына“ дигән беренче һәм икенче дәрәҗәле медаль кертү турында

Немец басып алучыларга каршы тылда партизаннар көрәшендә үзләрен аеруча күрсәткән ватан сугышы партизаннарын бүләкләү өчен, СССР Верховный Советы Президиумы **карар бирә:**

1. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче һәм икенче дәрәҗәле медаль кертергә.

2. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче һәм икенче дәрәҗәле медаль турындагы положениене расларга.

3. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче һәм икенче дәрәҗәле медальнең язма аңлатмасын расларга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
2 февраль, 1943 ел.

„ВАТАН СУГЫШЫ ПАРТИЗАНЫНА“ ДИГӘН БЕРЕНЧЕ ҺӘМ ИКЕНЧЕ ДӘРӘҖӘЛЕ МЕДАЛЬ ТУРЫНДА ПОЛОЖЕНИЕ

1. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче һәм икенче дәрәҗәле медаль белән безнең Совет Ватаны өчен, немец-фашист басып алучыларга каршы тылда партизаннар көрәшендә батырлык, чыдамлылык һәм кыюлык күрсәткән ватан сугышы партизаннары, партизан отрядларының начальниклар составы һәм партизаннар хәрәкәтен оештыручылар бүләкләнәләр.

2. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче һәм икенче дәрәҗәле медаль белән бүләкләү СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән партизаннар хәрәкәте Үзәк штабы начальнигы тарафыннан үткәрелә, бүләкләү соңыннан СССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан раслана.

3. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче дәрәҗәле медаль белән партизаннар, партизан отрядларының начальниклар составы һәм партизаннар хәрәкәтен оештыручылар, партизаннар хәрәкәтен оештыру эшендә аеруча хезмәт күрсәткән өчен, безнең ватаныбыз өчен немец-фашист басып алучыларның тылында партизаннар хәрәкәтендә батырлык, геройлыклары һәм күренекле уңышлары өчен бүләкләнәләр.

4. «Ватан сугышы партизанына» дигән икенче дәрәҗәле медаль белән партизаннар, партизан отрядларының начальниклар составы һәм партизаннар хәрәкәтен оештыручылар, командованиенең приказларын һәм заданиеләрен үтәүдә үзләрен аеруча күрсәткән өчен, немец-фашист басып алучыларга каршы партизаннар көрәшенә актив булышлык күрсәткән өчен бүләкләнәләр.

5. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче һәм икенче дәрәҗәле медальләрне тапшыру, партизаннар хәрәкәте Үзәк штабының вәкаләте буенча, бүләкләнүчеләр хәрәкәт итә торган урында партизан отрядларының командирлары тарафыннан алып барыла.

6. Немец-фашист басып алучыларга каршы көрәштә һәлак булган яки үлгән кешеләрнең «Ватан сугышы партизанына» дигән медале бу медаль белән бирелгән таныклык белән бергә бүләкләнүчеләрнең семьяларына бирелә һәм аларда истәлек булып саклана.

„ВАТАН СУГЫШЫ ПАРТИЗАНЫНА“ ДИГӘН МЕДАЛЬНЕҢ ЯЗМА АҢЛАТМАСЫ

1. «Ватан сугышы партизанына» дигән беренче дәрәҗәле медаль көмештән эшләнә, 32 миллиметр зурлыкта дөрес түгәрәк формада була.

Медальнең уң ягында—**В. И. Ленинның** һәм **И. В. Сталинның** күкрәктән профиль сурәтләре ясала.

Медальнең әйләнәсендә 4 миллиметр киңлектәге лентага «Ватан сугышы партизанына» дип язылган, аның башында һәм очында ике кечкенә йолдыз бар.

Медальнең түбәнге өлешендә, уртасында урак һәм чүкеч белән ясалган 5 почмаклы калку йолдыз һәм лентаның бөгелеп тора торган урыннарында һәр ике яктан «СССР» дигән хәрефләр язылган.

Медальнең сул ягында **«Безнең совет ватаныбыз өчен»** дигән язу бар.

Медальдәге барлык сурәтләр һәм язулар калку итеп ясалганнар.

Медаль алка һәм боҗра белән 20 миллиметр киңлектә ефәк муар лента белән капланган 5 почмаклы пластинка белән тоташтырыла.

Лента ачык яшел төстә, кырыйлары ике миллиметр киңлектә кызыл полосалар белән эшләнгән.

2. «Ватан сугышы партизанына» дигән икенче дәрәҗәле медаль җиздән эшләнә.

Лентасы ачык яшел төстә, кырыйлары 2 миллиметр киңлектәге күк полосалар белән эшләнгән.

Азат ителгән Шлиссельбург шәһәре урамнарында.

ТАСС фотохроникасы.

СТАЛИНГРАД УРАМНАРЫНДА

Шулай итеп, теләккә ирештек! Сталинград өстендә, аның үзәк өлеше өстендә яңадан кызыл байрак җилферди. Бу көнне—1943 нче елның 31 нче январен бөтен илебез хәтерләсен. Бу көнне Дон фронтының батыр гаскәрләре, башка частьлар белән бергәләп хәрәкәт итеп, фашистлар группировкасын юк иттеләр, бик күп санда гитлерчы солдатларны һәм офицерларны, 16 генералны пленга алдылар.

Безнең частьлар шәһәр урамнарында каты сугышлар алып барганнан соң дошманны флангылардан әйләнеп үттеләр.

Немецларның көчле ныгытмалары һәр җирдә дә өзелде. Бу ныгытмалар—мина кырларының, фланг утының, тимер чыбык тоткарлыкларының, баррикадаларның катлаулы системасыннан торган. Алар техника белән подваллар, блиндажлар һәм җимерелгән йортлардагы баскыч челтәрләре белән бик нык ныгытылган булган.

Шулай булуга да карамастан, бу система зур батырлык белән хәрәкәт иткән аз гына көчләр тарафыннан ватылды.

30 нчы январьда ук инде 62 нче армия районында Волга яры буенда немецлар пленныйлар ролендә күренә башладылар. Башта алар кечерәк группалар булып чыктылар, аннары акрынлап арттылар, һәм көн азагына инде чиксез күбәйделәр.

30 нчы январьда бөтен көн буе шәһәрдә кызу сугыш барды һәм фашистлар зур югалтуларга дучар ителделәр. 31 нче январьда иртә белән без бу югалтуларны үз күзләребез белән күрдек. Фашистларның үле гәүдәләре адым саен аунап ята иде, һәрбер ныгытылган узел янында яңа гына түгелгән кан эзләре күренә иде.

Сугыш төнлә дә туктамады. Безнең гаскәрләребезнең, шәһәрнең үзәге аркылы үтәргә омтылып, көньякта һәм көньяк-көнбатышта батырларча сугышуларын без белә идек. Көн азагына алар үтеп чыктылар һәм безнең башка гаскәрләребезгә үзләренең туганнарча сугышчан кулларын суздылар.

Шул ук төнне безнең әле сугыш алып баручы бер частебызга немецларның 14 нче танк дивизиясе командирының парламентеры килде. Ул, моннан ары каршылык күрсәтү тулысынча мәгънәсез булганлыктан, дивизия командирының үзенең штабы һәм бөтен дивизиясе белән берлектә пленга бирелүен тапшырды. Ул, иртәнге 6 сәгатькә дивизияне тулы поход тәртибендә театр янында тезеп тапшырырга вәгъдә иткән.

Таң атканда онытылмаслык картина күрергә мөмкин иде. Әле бөтен шәһәр ракеталар белән яктыртыла иде, атыш бара иде, безнең пушкалар һәм минометлар аталар иде, ә инде җимерелгән театр янында, тулы сугыш тәртибендә, кулларына кораллар тоткан һәм подразделениеләр башында командирлары торган хәлдә фашистларның танк дивизиясе калдыклары тезелеп тора иде. Дивизия шунда ук коралларын тапшырды.

Бу—эшнең башы гына иде. Буа бөселеп китте. Танк частьларының, кавалерия частьларының һәм башка частьларның калдыклары пленга бирелә башладылар. Сталинград урамнары яңадан фашистлар белән тулды, ләкин инде алар коралсызлар, ябыклар, кырынмаганнар; чүпрәк-чапракка киенгәннәр иде. Алар, кулларын югары күтәреп, автоматларын аяк араларына кыстырып, блиндажлардан чыгалар.

Пленныйларны санап өлгерергә мөмкин түгел. Мәйданнарда алар инде меңәрләп җыелганнар. Аларның күбесе урамнарда йөриләр һәм бер төрле сорау бирәләр:

— Плен кайда монда?

Мина кыры аркылы яна гына салынган тар сукмактан без Волга яры буйлап яз кояшыдай җылы кояш астында пристаньга таба барабыз. Әле пленга бирелмәгән фашист башкисәрләр—снайперлар аталар, ә безнең саперлар күп санлы мина кырларын әле арындырырга гына керешәләр, ә урамнарда инде җанлылык.

Менә Кострома урамы. Теткәләнеп беткән баганада иске почта ящигы эленеп тора, җимерелгән йортларның стеналарында август аенда элгән: «Сталинград фашистларныкы булмас!» дигән лозунглар сакланып калган.

Саргаеп беткән әлеке безнең плакат кисәкләре белән янәшә немецлар комендатурасының приказлары эленеп тора. Мәйданнар каскалар белән, кичә һәм моннан ярты сәгать элек үтерелгән немецларның гәүдәләре белән тулган.

Монда һәркем пистолетын һәм автоматын әзер хәлдә йөртә.

Немец телендә язылган юл күрсәткечләр әле алып ташланмаган, ләкин баганаларга алардан түбәнрәк итеп инде рус телендә «На Волгу—прямо» дигән язулар ябыштырылган.

Үзәк урамнарның берсендә—фашистларның каберлеге. Анда акбурга буялган баганалар тора, ә аларның өстенә курkыныч итеп аклы-каралы тимер тәре сурәте төшерелгән. Каберлек белән янәшәдә, тишелгән башы белән кабер өстендәге баганага терәлеп, бер фашист ята—аны күмәргә өлгермәгәннәр. Үлекләр һәр җирдә аунап ята, кай җирләрдә алар дистәләп.

Таза пленныйлар авыруларны һәм яралыларны лазаретларга алып баралар. Менә немецлар лазареты. Ул подвалда урнашкан. Шуларның берсенә керәм.

Подвалның эчендә яралы 3.000 ләп солдат һәм офицер бар. Алар идәндә, чүпрәкләр өстендә яталар, алар арасында инде үлгәннәре дә бик күп: кайберләре яралардан, салкыннан һәм ачлыктан үләләр.

Монда түзеп булмаслык дәрәҗәдә сасы, ыңгырашулар, акырулар—болар барысы да безне шунда ук югарыга — Сталинград урамнарына чыгарга мәҗбүр итә.

Монда эш кайный, трофейлар саныйлар, автомобильләрне, орудиеләрне сортларга аералар. Автоматлар һәм винтовкалар әрдәнәләп өелгән һәм бу әрдәнәләр үскәннән-үсеп тора, чөнки яңадан-яңа пленныйлар группалары өзлексез рәвештә килеп коралларын ташлап торалар.

Җирле халыклар үзләренең качкан урыннарыннан чыгалар һәм шатлыкларыннан җылыйлар. Сугышчылар җимерек йортларның иң биекләренә менеп, аларга кызыл байраклар кадыйлар. Алар инде бик күп, алар һаваның зәңгәр фонында ялкынланып җилфердиләр, һәм түбәннән үтеп баручы сугышчылар аларны олылап честь биреп китәләр.

НИКОЛАЙ ВИРТА.

СТАЛИНГРАД, 1 февраль. (Телеграф буенча).

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

3 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

3 нче февральгә каршы төндә **Көньяк-Көнбатыш, Көньяк, Төньяк Кавказ, Закавказье, Воронеж, Ленинград** һәм **Волхов** фронтлары гаскәрләре әлекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Көньяк фронтта Н-че берләшмә частьлары, бик каты сугышлар нәтиҗәсендә, немецларны халык яши торган өч пункттан бәреп чыгардылар. Дошман контратака ясап карады, ләкин үзе өчен зур югалтулар белән алып ташланды. Немецларның 6 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр дошманның көчле рәвештә ныгытылган терәк пунктын алдылар һәм 7 пулемет, танкка каршы ата торган 4 мылтык, берничә дистә автомат һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерделәр.

* * *

Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары, танкистлар белән бергә хәрәкәт итеп, халык яши торган өч пунктны алдылар һәм дошманны кысырыклауны дәвам иттерделәр. Гвардияче бер берләшмә частьлары каты сугышларда немецларның каршылык күрсәтүен бастырдылар, алга киттеләр һәм халык яши торган 10 пунктны алдылар. 26 орудие, 30 автомашина, 6 тягач, 3 радиостанция һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерелде. 60 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Бер батальонга якын немец пехотасы, дошманның 27 орудиесе, 8 минометы һәм 21 автомашинасы юк ителде.

Безнең очучылар Ворошиловград аэродромына һөҗүм ясадылар һәм немецларның 15 самолетын юк иттеләр. Шуның өстенә һава сугышларында дошманның 8 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Воронеждан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта немецлар контратакага күчтеләр. Совет сугышчылары, омтылышлы удар ясап, дошманны аударып ташладылар һәм халык яши торган ике зур пунктны алдылар. Н-че берләшмә частьлары гитлерчыларны халык яши торган ел пункттан бәреп чыгардылар. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 12 орудие, 27 пулемет, 6 миномет, сугыш припаслары төялгән 18 автомашина һәм сугыш милекләре тутырылган бер склад бар.

* * *

Төньяк Кавказ гаскәрләре, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Халык яши торган бер пункт өчен булган сугышларда безнең сугышчылар дошманның ике рота пехотасын тар-мар иттеләр һәм 4 танкысын сафтан чыгардылар. 2 орудие, 8 пулемет, 5 миномет һәм миналар складын кулга төшерелде. Икенче бер участокта гвардияче кавалеристлар немецларның бер обозына атака ясадылар. Сугыш йөкләре төялгән 20 автомашина һәм 27 повозка кулга төшерелде.

* * *

Калинин өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды төнлә белән немецларның гарнизонына һөҗүм итеп, комендатураны туздырган һәм 26 гитлерчыны кырып ташлаган. Берничә көн үткәч шул ук отрядның партизаннары ике сәгать дәвам иткән сугышта 30 немец солдатын юк иткәннәр. Калинин партизаннарының бер группасы немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Паровоз һәм 4 платформа җимерелгән. Күп вагоннар һәм платформалар зарарланган.

* * *

Түбәндә Сталинград өлкәсенең Ермохинский хуторында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Гитлерчылар колхозның бөтен байлыкларын таладылар, халыкның 770 баш терлеген, 350 пот ашлыгын, бик күп продуктларын һәм төрле кыйммәтле әйберләрен талап алдылар. Немецлар мәктәпне, уку өен, амбулаторияне, аптеканы һәм ветеринария пунктын туздырдылар һәм юк иттеләр. Колхозга һәм колхозчыларга китерелгән зыян берничә миллион сумга җитә. Җан кыючы фашистлар хутордагы 10 кешене: 15 яшьлек Гавриил Слесаревны, 25 яшьлек Татьяна Антонованы, 57 яшьлек Иван Никулинны, 54 яшьлек Федосья Гусеваны, 65 яшьлек Семен Поляковны һәм башкаларны атып үтерделәр. Чигенер алдыннан немецлар барлык җәмәгать биналарын һәм 16 колхозчы йортын яндырдылар». Актка авыл советы председателе Прохоров, укытучы Буков, колхозчылардан И. Пельщуков, Е. Камышанова, Е. Аверкин һәм башкалар кул куйды.

3 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

3 нче февральда Курскидан төньяктарак булган районда безнең гаскәрләр **Золотухино** һәм **Возы** тимер юл станцияләрен алдылар һәм, шулай итеп, **Курск** белән **Орел** арасындагы тимер юлны кистеләр.

Украинада безнең гаскәрләр **Красный Лиман** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, **Купянск** тимер юл узелын, шулай ук **Кременная** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Рубежное** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Пролетарск** шәһәрен алдылар.

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, **Кущевская** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, шулай ук район үзәкләреннән **Кагальницкаяны, Ленинградскаяны, Крыловскаяны** алдылар.

Башка фронтларда безнең гаскәрләр әлекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльлар дошманның 10.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* * *

2 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 8 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Көньяк фронт гаскәрләре, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Н-че часть автоматчиклары, 10 танкка утырып, халык яши торган бер зур пунктка бәреп кергәләр һәм бик каты сугыш нәтиҗәсендә аны алдылар. Халык яши торган пунктка килү юлларында һәм аның урамнарында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре калды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Икенче бер участокта Н-че берләшмә частьлары халык яши торган берничә пунктны алдылар. Немецларның 3 танкысы, 2 самоход орудиесе, 27 пулеметы, 3 сугыш припаслары складын һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Сватово районында безнең частьлар халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. 800 гә якын гитлерчы кырып ташланды, немецларның 5 танкысы, 2 бронемашинасы һәм 24 орудиесе юк ителде. 17 орудие, бер сугыш припаслары складын, 60 автомашина, 11 радиостанция, ашлык тутырылган бер элеватор һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

Безнең очучылар һава сугышларында немецларның 10 самолетын бәреп төшерделәр.

Воронеждан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Горшечнаядан төньяк-көнбатыштарак совет частьлары дошманның чолганып алынган группасын юк итүне дәвам иттерделәр. 600 кеше плен алынды. Кулга төшерелгән трофейлар арасында 100 автомашина, 20 мотоцикл, 300 ат, 200 повозка һәм күп кенә төрле кораллар бар. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм чигенүче гитлерчыларны куып барып, 400 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырдылар. 650 кеше плен алынды.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, алга таба барып, немецларның бер батальон пехотасын һәм бер эскадрон кавалериясен тар-мар иттеләр. 4 танк, 15 орудие, 21 пулемет, танкка каршы ата торган 11 мылтык шулай ук сугыш припаслары һәм гитлерчылар тарафыннан җирле халыктан талап алынган милекләр төялгән 22 автомашина кулга төшерелде. Икенче бер участокта совет кавалеристлары немецларны халык яши торган ике зур пункттан бәреп чыгардылар һәм бик күп трофейлар кулга төшерделәр.

Шушы көннәрдә үзәк фронтның бер участогында полковник Курсаков командалыгындагы кавалерия группасы сугыша-сугыша дошман тылыннан чыкты. Ноябрь ахырында кавалерия группасы дошман тылына барып чыгып, бик әһәмиятле бер тимер юл магистрален алып, бу юлда һәр

(Ахыры 4 нче биттә).

ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕНӘ ӘЗЕРЛЕКНЕ ФРОНТТАГЫЧА КЫЗУ ТЕМПЛАР БЕЛӘН АЛЫП БАРЫРГА!

Рәсемдә: Вахитов исемендәге жиркомбинатның алдынгы токаре Николай Александрович Егоров. Ул норманы системалы рәвештә 200 процент үти.

Б. Невзоров фотосы.

Батыр сугышчыларга бәйрәм бүләкләре

БАЛТАЧ. (Телефон буенча). Район колхозларында батыр сугышчыларга бүләкләр җыю уңышлы бара. Калинин исемендәге колхоз члены Хәмитов бер каз, Низамиев бер үрдәк бүләк иттеләр.

Район буенча 18,45 центнер ит, 1.400 литр сөт, 235 килограмм бал, 206 килограмм суган, 33 килограмм киптерелгән бәрәңге һәм 93 килограмм сухари, 85 пар бияләй, 35 оекбаш бүләк иттеләр.

«Кызыл Октябрь» колхозындагы агитколлектив җитәкчесе иптәш Галләмова аеруча яхшы эшли. Колхозчылар 12 килограмм бал, 95 килограмм сухари, 86 килограмм ит, оекбашлар һәм башка төрле әйберләр бирделәр. Ворошилов исемендәге колхозда 650 килограмм бәрәңге, 1,5 центнер ит, күп кенә бал һәм башка әйберләр җыелды. Бүләкләр җыю дәвам итә.

* * *

ЧИСТАЙ. (Телефон буенча). Колхозчылар батыр сугышчыларга бүләкләр җыюны киң рәвештә җәелдереп җибәрделәр. Шонталы авыл советына караган «Чаткы» колхозы членнары батыр сугышчыларга 600 килограмм бәрәңге, 139 стакан тәмәке, 7 пар йон бияләй, оекбаш һәм башка күп кенә әйберләр бүләк иттеләр.

«Красный пролетарий» колхозы членнары 85 килограмм ит, «Красный партизан» колхозы—80 килограмм ит һәм Молотов исемендәге колхоз членнары 80 килограмм ит тапшырдылар.

ӘЗЕРЛЕК УҢЫШЛЫ БАРА

Дөбьяз районы, «Кызыл юл» колхозы (председателе иптәш Хәмидуллин) 1942 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы рәвештә төгәлләде. Дәүләткә ашлык һәм яшелчә тапшыруны, МТС эшләре өчен натуралата түләүне вакытында 100 проценты белән үтәде. Дәүләт каршындагы башка төр йөкләмәләр дә (ит, сөт, йон һ. б.) уңышлы үтәлде.

«Кызыл юл» колхозы 1943 нче елда хәрби уңышны яулап алу өчен фронттагыча көрәшә. Колхозчылар язгы чәчүгә әзерләнү буенча аерым тармакларга беркетелгәннәр. Чәчүлек өчен план буенча 283 центнер орлык кирәк иде, 285 центнер ашлык триер аркылы үткәрелеп, чистартылып, яхшы саклана торган урынга алынып куелды инде. Орлыкларның кондициясе яхшы нәтиҗәләр бирде.

Агротехника чараларының үтәлеше дә әйбәт. Кырга 850 тонна тирес чыгарылды, 70 центнер көл, 5 тонна фикаль җыеп куелды. Аларны җыйнау әле һаман дәвам итә. Кар тигез ятмый торган җирләрдә, 160 гектар мәйданда кар тотылды.

Тарту көчләрен әзерләүгә зур әһәмият бирелә. Атларны язгы чәчүгә әзерләү буенча зур көч куелды. Язгы чәчү вакытында файдалану өчен (хәзер дә файдаланылалар), эре мөгезле терлекләрне җигәргә өйрәтелә. Хәзер 3 сыер җигәргә өйрәтеп, эштә файдаланыла башлады.

Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм сбруйларга ремонт үткәрү төгәлләнү алдында тора. Ремонтның сыйфаты яхшы. Авыл хуҗалыгы эшләрендә тәҗрибәле картларның белемнәрен башкаларга да күчерү чарасы күрелә. Колхозның агротехнигы иптәш Мөхәмәтшина агротехника укуларын оештыруда зур активлык күрсәтә. Агротехника укуларын колхоз председателе иптәш Хәмидуллин, агротехник Мөхәмәтшина һәм башка тәҗрибәле иптәшләр алып баралар. Агротехника укуларының 7 занятиесе булды инде.

З. КАРАМОВ.

„Байкал“ колхозында

Саба районының «Байкал» колхозында барлык эш ватан сугышы таләп иткәнчә үткәрелә. Колхозчылар һәрбер эшне намус белән башкаралар, фронтка ярдәм итүгә барлык көчләрен бирәләр. Бу колхоз дәүләткә ашлык тапшыруны 1942 нче елда ук 104 процент итеп үтәде.

Колхоз 1943 нче елгы язгы чәчүгә әзрлекне яхшы оештырды. 10 төрле культура буенча чәчүлек орлык әзерләнеп куелды инде. План буенча 789 центнер орлык кирәк иде. Бу сан 120 центнерга арттырып әзерләнде. Тамыр азыклар буенча да чәчүлек орлыклар тулысынча әзерләнеп, коры урыннарда сакланалар.

Авыл хуҗалыгы машиналарын язгы эшләргә кадәр төзек хәлгә китерергә нык игътибар бирелә. Ремонт якын көннәрдә төгәлләнәчәк. Арбалар һәм сбруйлар әзерләү дә яхшы оештырылган.

Язгы эшләргә әзерлек белән бергә терлекләрне кышлатуны нормаль алып баруга да бик нык әһәмият бирелә. Колхозның сыерлары, сарыклары, каз һәм тавыклары, йорт куяннары кышны җылы һәм тук кышлатылалар. Фермаларда яшь терлекләрне исән-сау алып, тәрбияләп үстерү өчен кирәкле шартлар тудырылган.

Д. ГУМЕРОВ.

УРЫНСЫЗ ТЫНЫЧЛАНАЛАР

Язгы эшләргә әзерлекнең төгәлләнер вакыты җитә. 1943 нче елда мул иген уңышы алырга тырышучы колхозлар язгы чәчүгә әзерлекне оештыруга зур әһәмият бирәләр. Биектау районының «Урал» колхозы чәчүлек орлыкларны ноябрь аенда ук сугып, чистартып салды. Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм сбруйларга ремонт шушы көннәрдә төгәлләнде. Хәзер биредә кышкы агротехника чаралары үткәрелә. Басуга 150 йөк тирес чыгарылды, 20 центнер көл җыелды. «Трактор» колхозында да орлык һәм авыл хуҗалыгы инвентарьлары әзер инде. Атлар тәрбиясен яхшырту чаралары күрелде. Алар өчен язгы чәчү чорына җитәрлек кадәр азык та әзерләп куелды. «Кызыл кул», «Искра» колхозларында да язгы эшләргә әзерлек яхшы.

Ләкин районда, язга кадәр вакыт күп әле, өлгерербез, дип урынсыз тынычланучы колхоз җитәкчеләре дә бар. Менә Молотов исемендәге колхоз. Биредә ашлык сугу бик озакка сузылды һәм язгы чәчүгә дә әзерлек башланмаган әле.

«Парижская коммуна» авыл хуҗалыгы артелендә дә шушы ук хәл. Бу колхоз урып-җыюны, ашлык сугу һәм дәүләткә ашлык тапшыруны районда беренче булып төгәлләгән иде. Шундый алдынгы колхозның 1943 нче елда иген уңышын тагын да күтәрү өчен көрәшне оештырмавы бик гаҗәп хәл. «Дружба», «Спартак», Киров һәм Ленин исемендәге колхозлар да кышны әрәм үткәрәләр. Язны әзерлек белән каршылау чарасын күрмиләр.

Д. СКВОРЦОВ.

ЮГАРЫ УҢЫШ АЛУ ӨЧЕН!

«Степан Разин» колхозы Красный Бор районында алдынгы колхозлардан санала. Ул узган елда иген уңышын тулысынча җыеп алып, дәүләткә ашлык тапшыру, печән әзерләү һәм башка йөкләмәләрне вакытында үтәде Шулар өстенә оборона фондына 490 центнер ашлык бирде. Колхоз председателе иптәш Шәйдуллин.

— Эшне соңарту, аларны чиратлаштыру, икенче эшне башкаруны тоткарлый. Шуңа күрә колхоздагы эшләрне үз вакытында бер үк темп белән дәвам иттерәбез. Язгы чәчүгә көздән үк әзерләнә башладык,— ди.

Бу колхозда чәчүлек орлыклар тазартылып, җитәрлек күләмдә салынган инде. Орлыкларның сыйфаты тикшерелде һәм яхшы дип табылды. Чәчү машиналарына ремонт ясау уңышлы бара. 13 чәчү машиналарына ремонтны февраль башында төгәлләү планлаштырылды.

АТ БАР, СБРУЙ ЮК

ЧЕПЬЯ. (**Үз хәбәрчебездән**). Колхозда авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы һәм үз вакытында башкару арба, чана, камыт, ыңгырчак һәм башка сбруйларның барлык атларга дә җитәрлек булуына бик нык бәйләнгән. Сталин исемендәге колхоз мисалында моны бик ачык күрергә мөмкин. Барлык эш атларына да җитәрлек сбруйлар булмау нәтиҗәсендә, колхоз председателенең бер генә наряды да тулысынча үтәлми. Колхоз авыл хуҗалыгы эшләрен вакытында башкара алмый. Бу хәл 1942 нче елның июнь аена кадәр дәвам итә.

Колхозда җитәкчелек алмашына. Анда председательлеккә иптәш Нәбиева сайлана. Һәм эшләр үзгәреп китә. Иптәш Нәбиева, председатель булуының беренче көненнән үк, барлык атларга да тулы комплект сбруй әзерләү турында кайгырта башлый. Бик кыска вакыт эчендә 45 җигү атының барысына да камыт, ыңгырчак, йөгән, арба, чана әзерләнә. Сбруйларны ат җигүче колхозчыларга биреп, эштән кайткач кабул итеп алу өчен аерым кешеләр билгеләнә. Алар бер үк вакытта ватык сбруйларны да төзәтеп торалар. Мондый тәртип сбруйларны югалтуга, саксыз йөртүләргә чик куя. Һәркем үзе җигеп йөри торган сбруйны төзек тотарга тырыша.

Сбруйларны җитәрлек әзерләгәч, ат көчләреннән тулысынча файдалану мөмкинлеге туа. Колхозда ашлык сугу ноябрьда ук төгәлләнә. Терлекләргә кыш буе ашатырга җитәрлек тупас азыклар ферма тирәсенә ташып куела. Башка эшләр дә уңышлы башкарыла. 1942 нче елның 6 ае эчендә генә дә атлар белән эшләүдән колхозда 34.300 сумлык доход алына.

Бу колхоздан 5 километр гына ераклыктагы «Ирек» колхозында ат сбруйлары белән эш бөтенләй башкача. «Ирек» колхозында ат сбруйларына карата хуҗасызлык хөкем сөрә. 1942 нче елның беренче январена колхозда 29 чана, 35 йөк камыты, 36 сабан камыты, 40 ыңгырчак, 40 дуга, 25 дилбегә, 18 аркан була. Болар эш атларының 40 процентын да тәэмин итәрлек түгел иде, әлбәттә. Ләкин саксызлык һәм хуҗасызлык аркасында хәзер аларның да күбесе югалтылган. Мәсәлән 12 камытның, 15 ыңгырчакның, 8 дуганың, 13 дилбегәнең, 5 арканның кая китүен бер кеше дә белми. Сбруйлар колхозчыларның үз кулларында саклана. Шуңлыктан, булган сбруйлар да колхоз эшендә тулысынча файдаланылмый, нарядлар үтәлми. Колхоз члены Газин сельпога товар алып кайту өчен күрше заводка барырга наряд ала. Ул, сбруй таба алмаганлыктан, икенче көнне генә юлга чыгып китә. Тагын бер факт. Атларга ашату өчен кырдан вика алып кайтырга беренче бригадага наряд бирелә. Бригада члены викага бару өчен көн буе дилбегә эзли. Ләкин тапмый. Дилбегә булмаганлыктан вика алып кайтылмый, атлар ач куна. Сбруйларның җитәрлек булмавы авыл хуҗалыгы эшләренең барлык тармакларындагы эшне башкаруда да зур уңайсызлыклар тудыра.

Эш атларына сбруйлар җитәрлек булмаган колхозлар районда байтак. Буденный исемендәге колхозда сбруй булмаганлыктан атларның 50 проценты да файдаланылмый. «Крестьянская газета», «Правда» колхозларында да шундый ук хәл.

Арба, чана һәм башка сбруйлар районнагы эш атларының 57 процентын гына тәэмин итәрлек. Ә районда сбруйлар эшләү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Яңа чаналар ясау һәм искеләрен ремонтлау өчен «Кызыл Октябрь» артеле берничә колхозда мастерскойлар оештырган. Аларның эшли башлавына күп кенә вакытлар үткән. Ләкин, материаллар белән тиешенчә тәэмин ителмәү нәтиҗәсендә, кыш буена 100—150 чана гына эшләп чыгарганнар. Камыт җитми, ә камыт эшләү өчен киндер юк. Диләр колхоз председательләре. Чепья районы хатын-кызлары суккан киндер бөтен тирә-якта дан тота. Җитен, киндер суга ала торган кешеләр анда шулай күп булса да, бу эш урында тиешенчә оештырылмаган. Дугалар булмау аркасында да колхозлар зур уңайсызлыкларга очрыйлар. Председателе иптәш Әүхәдиев булган «Кызыл Октябрь» артеле моннан бер ел элек 600 дуга эшләткән. Ләкин аларны колхозларга сату эше белән беркем дә шөгыльләнми. Әзерләнгән бер тонна бау да шулай ук артель складында инде 170 көн буе хәрәкәтсез ята. Райпотребсоюз председателе иптәш Сафиуллин да артельләр җитештергән товарны үз вакытында сату өчен көрәшми.

Бу фактлар Чепья районының авыл хуҗалыгы эшләрен башкаруда ни өчен артта калуы турында сөйлиләр. Шулай булгач, район һәм колхоз җитәкчеләренең һәрвакыт, сбруйлар җитәрлек булмаганлыктан ат көчләреннән тулы файдаланып булмый, дип зарлануларын ничек дип бәяләргә?

Ф. ГАЛИЕВА.

Совет Информбюросыннан

3 нче ФЕВРАЛЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Башы 2 нче биттә)

төрле хәрәкәтне какшаткан иде һәм күп көнә көннәр буена аны сугыша-сугыша үз кулында тотып торган иде. Соңга табарак кавалерия группасы, командованиенең приказы буенча, дошманның тирән тылына үтеп чыкты, дошманның гарнизоннарын туздырды, күперләрне һәм тимер юлларны шартлатты, элемтә средстволарын җимерде, шулай итеп дошманның тылын төрлечә какшатты.

Үтеп чыккан чакта булган сугышларда һәм дошман тылларында үткәрелгән 40 көнлек рейд вакытында кавалерия группасы дошманның 6 самолетын, 40 тан артык танкысын, 46 орудиесен, 40 станоклы һәм кул пулеметларын, 300 автомашинасын һәм мотоциклларын, шулай ук бик күп башка төрле сугыш материалларын юк иткән. Шул ук вакыт эчендә кавалерия группасы немецларның 8 гарнизонын юк иткән һәм 4000 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын кырып ташлаган. Командованиенең заданиесен үтәгәннән соң кавалерия группасы дошман тылыннан чыкты һәм Кызыл Армия частьларына кушылды.

* * *

Январь ахырында немецлар Ленинград партизаннарының бер отрядына каршы җәза экспедициясе җибәргәннәр. Совет патриотлары, дошманның планын вакытында белеп, гитлерчыларга каршы үзләре атака ясаганнар һәм аларны зур югалтуларга дучар иткәннәр. Икенче бер отрядның партизаннары дошманның гаскәрләр һәм сугыш техникасы төялгән бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар.

ФРОНТ ЛИНИЯСЕНЕҢ ТЕГЕ ЯГЫНДА

Шушы көннәрдә Смоленск өлкәсенең Н. районындагы ВКП(б) райкомы секретаре фронт линиясе аша үтеп чыкты. Ул түбәндәгеләрне хәбәр итте:

— Немецлар тарафыннан оккупацияләнгән районнарның халыклары Кызыл Армиянең уңышлары турында ишеткәч, немец басып алучыларга каршы көрәшне тагын да көчәйттеләр.

Күп кенә авылларда булып үткән яшерен җыелышларда иптәш Сталинның Октябрьның XXV еллыгы турындагы доклады һәм Совет Информбюросының соңгы белдерүләре укылды. Җыелышта катнашучылар кулларыннан килгән бөтен нәрсә белән Кызыл Армиягә ярдәм итәргә карар бирделәр.

Оккупацияләнгән районнарның халыклары «Смоленск партизаны» исемле танклар колоннасы төзүгә акча җыялар. Бер районда торучылар инде 114 мең сум акча җыйганнар. Күрше районда да 100 мең сум җыелды.

Партизаннар отрядының элемтәчеләре берничә тапкыр фронт линиясе аша үтеп чыктылар. Алар хатлар җыйдылар һәм аларны оккупацияләнгән районнарда торучыларга илтеп тапшырдылар. Яңадан әйләнеп килгәндә элемтәчеләр ватан сугышы фронты сугышчыларына хатлар алып килделәр.

Элемтәче-партизаннар кыска гына вакыт эчендә колхозчыларга 7 меңгә якын хат тапшырдылар.

СТАЛИНГРАД ЯНЫНДА НЕМЕЦ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ЮК ИТЕЛҮЕ УҢАЕ БЕЛӘН ГЕРМАНИЯДӘ КАЙГЫ

ЖЕНЕВА, 3 февраль. (ТАСС). Сталинград янында Германия гаскәрләренең туздырылуы һәм юк ителүе уңае белән Берлинда бөтен Германиядә кайгы игълан итү турында боерык чыккан. Геббельсның приказы буенча 4 нче февральдән 6 нчы февральгә кадәр барлык күңел ачу учреждениеләре ябык булырга тиеш.

„ХӘЗЕРГЕ СУГЫШТА ГАЯТЬ ЗУР ҖИҢҮ"

Сталинград янында немец-фашист гаскәрләренең чолганып алынуы һәм бетерелүе турында Америка матбугаты

НЬЮ-ЙОРК, 2 февраль. (ТАСС). Сталинград янында чолганып алынган немец-фашист гаскәрләренең Кызыл Армия тарафыннан бетерелүенә һәм 16 генералның плен алынуына аңлатма биреп, «Сэн» газетасы болай дип яза: «Сталинград фронтыннан алына торган хәбәрләр, 30 нчы январьда Берлинда Герингның һәм Геббельсның кайгылы чыгышларына бик яхшы аңлатма булып торалар. Хәзер, алданган немец халкына Гитлерның турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә ни сәбәптән батырчылык күрсәтә алмаганлыгы ачык. 1941 нче елның июнь аенда Германия халкына Россия берничә атна эчендә «юк ителер» дип вәгъдә ителгән иде бит. Шул ук елның декабрь аенда немецларга эш «беркадәр тоткарлана», ләкин тиздән «бөтенесе дә тәртиптә булыр» дип әйткәннәр иде. 1942 нче елның язына немецларга, тагын тик бер генә җәйге кампания кирәк булачак, һәм рус гаскәрләре Урал артына куып җибәреләчәк, дип әйттеләр. Узган көз көнендә Гитлер Сталинградны алырга вәгъдә итте, ә бүген гитлерчылар Сталинград янында камалып алынган армияләренең үлекләр армиясе булуы уңае белән ыңгырашалар. Хәзер Германия халкы Гитлерның, Герингның һәм башка гитлерчы башлыкларның барлык вәгъдәләре турында нәрсә уйлый алыр икән?».

Ассошиэйтед Пресс агентлыгының күзәтүчесе Грэнмер Сталинград янында Кызыл Армиянең җиңүенә хәзерге бөтен сугышта иң зур җиңү дип бәя бирә.

«Нью-Йорк геральд трибюн» газетасының хәрби күзәтүчесе Элиотның фикеренчә, немецлар үткән елның җәйге кампаниясе чорындагы барлык уңышларның җимешләреннән мәхрүм булалар. «Немец гаскәрләренең мораль хәле һәм аларның дәрәҗәсе гадәттән тыш түбән төште, чөнки Кызыл Армия Германия гаскәрләренең һөҗүмен туктату гына түгел, бәлки аларны элекке позицияләренә алып ташлады, шул ук вакытта немецлар үлгән, плен төшкән хәлдә һәм техника ягыннан гаять зур югалтуларга дучар ителделәр. Немецлар Төньяк Африкада җиңелүләрен коммуникацияләрнең начар булуы һәм сугышның бу театрында кулларындагы гаскәрләрнең аз санда булуы белән аңлата алырлар. Ләкин Кызыл Армия Германиянең кулларында гаять зур ресурслары булган армияләрен тар-мар итә, шунлыктан Россиядә нәрсә булганлыкны аңларга немецларның кулларыннан килми».

„СТАЛИНГРАД ЯНЫНДА НЕМЕЦЛАРГА ГАЯТЬ ЗУР КҮЛӘМДӘ СУГЫШ ҺӘЛАКӘТЕ КИЛДЕ"

АНГЛИЯ МАТБУГАТЫНЫҢ АҢЛАТМАЛАРЫ

ЛОНДОН, 2 февраль. (ТАСС). Англия матбугаты Сталинград янында чолганып алынган немец-фашист гаскәрләренең тәмам бетерелүе гаять зур әһәмияткә ия булганлыкны күрсәтә. «Дейли мэйл» газетасы, бу гаскәрләрне бетерү белән хәзерге кампаниянең бөтен бер этабы төгәлләнде, дип яза. Сталинград янында Германия гаскәрләрен чолгап алу һәм юк итү буенча алып барылган операцияләр стратегия һәм мораль яктан гаять зур әһәмиятле урын тота. Газета, Төньяк Кавказда Германия гаскәрләренең җитди куркыныч алдында торганлыкларын аеруча күрсәтә.

«Дейли экспресс» газетасының хәрби күзәтүчесе Морлей Ричардс болай дип яза: «Генерал-фельдмаршал Паулюс пленга бирелде һәм немецларның алтынчы армиясе юк ителде. Сталинград янында немецларның 330 мең кешедән торган группировкасын чолгап алу һәм бетерү, немецларга гаять зур күләмдә сугыш һәлакәте килде дигән сүз. Германиянең алтынчы армиясе капкынга эләкте. Руслар баштарак бу армиянең басымын бик осталык белән тоткарларга, ә соңыннан аны юк итәргә булдыра алдылар. Сталинградны алырга исәп тотып Гитлер яңадан бик тупас ялгышу ясады. Гитлер үзенең дәрәҗәсен саклау өчен Сталинград янындагы гаскәрләрен әле вакыт бар чагында кайтарып җибәрергә теләмәде. Ул бу гаскәрләрне үзенең дәрәҗәсенә корбан итте. Сталинград районында Германия группировкасының бетерелүе Гитлерның хәрби яктан гаять надан икәнлеген күрсәтеп тора».

СТАЛИНГРАД ОБОРОНАСЫ — БЕЗНЕН ЭПОХАБЫЗ ТАРИХЫНДА ИҢ ГЕРОИК БҮЛӘК"

Кызыл Армиянең сугыштагы уңышлары турында Төркия матбугаты

ИСТАМБУЛ, 2 февраль. (ТАСС). Төркия газеталары Совет—Германия фронтыннан алына торган хәбәрләргә электәгечә гаять зур әһәмият бирәләр һәм Сталинград янында чолганып алынган немец-фашист гаскәрләренең бетерелүен аеруча күрсәтеп язалар. «Вакыт» газетасында Садри Эртем, Сталинград оборонасы безнең эпохабыз тарихында иң героик бүлек булып тора, дип яза. Кешелек тарихы бу шәһәрне саклаган барлык кешеләрне геройлар дип хәтергә төшерер. Сталинград немецларның басымнарына каршы чыдап торды, һәм бу нәрсә Германиянең барлык стратегия планының җимерелүенә һәм Германия гаскәрләренең җиңелүенә китерде.

«Еңи сабах» газетасы редакторы Ялчин, быелгы кыш көнендә Германия армияләре тынычлыкны күрә алмаячаклар дип яза. Бу хәл немецларны куркыта. Германия армиясенең арганлыгы һәм хәлсезләнү билгеләре торган саен ачыграк күренә бара». Русларның ике айдан артык кышкы һөҗүмнәре вакытында немецлар очраган котточкыч югалтуларны немецлар ничек кайтара алырлар икән, дигән сорауны бирергә мөмкин. Быелгы кыш көнендә немецлар арганлыкның һәм көч бетүнең нәрсә икәнлеген тулысынча аңладылар. Моннан соң Германия өчен сугышның һөҗүм стадиясе тәмам булды инде.

Жиро белән де Голль арасындагы сөйләшүләргә карата

ЛОНДОН, 1 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, генерал Жиро хәзерге вакытта французлар хәрәкәтенең берничи дә бердәмлеге күренмәгәнлеген белдергән. Аның белән генерал де Голль арасында бары тик «хәрби, экономик һәм финанс мәсьәләләре турында» гына килешүгә ирешелгән.

Рейтер агентлыгы дипломатия күзәтчесенең хәбәр итүенә караганда, Лондонда де Голльнең баш ставкасы янында генерал Жироның махсус илчелеге төзеләчәк. Франция милли комитетының шундый ук илчелеге Алжирда генерал Жиро янында да оештырылачак. Бу илчелекләр икесе дә хәрби, экономик һәм техник мәсьәләләр белән шөгыльләнәчәкләр, ләкин аларга берничи дә политик функцияләр йөкләнмәячәк. Жиро белән де Голль арасында алып барылган сөйләшүләргә кагылып, күзәтүче түбәндәгеләрне күрсәтә: алар политик проблемалар турында да киңәшкәннәр, ләкин хәзерге вакытта һәр ике якның позицияләре арасындагы фикер башкалыкларын бетерергә мөмкин булмаган. Де Голль республика законнарын саклау һәм Виши хөкүмәте янындагы элементларны алып ташлау нигезендә политик власть төзүне таләп итә. Жиро хәзерге вакытта де Голльнең бу тәкъдимнәрен кабул итүне мөмкин дип тапмый.

АФИ агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Сугышучы Франция даирәләрендә де Голль белән Жиро арасындагы сөйләшүләр вакытында кузгатылган барлык проблемаларны хәзерге шартларда кичекмәстән һәм бөтенләйгә хәл итүгә исәп тотарга мөмкин түгел.

ТӨРКИЯНЕҢ ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ БЕЛӘН ЧЕРЧИЛЛЬНЕҢ СӨЙЛӘШҮЛӘРЕ

ЛОНДОН, 1 февраль. (ТАСС). Бүген Англиянең информация министрлыгы белдерү чыгарды. Белдерүдә болай диелә:

«Берләшкән Корольлек хөкүмәтенең вәкиле булган баш министр Уинстон Черчилль Төркия республикасы хөкүмәтенең кунагы сыйфатында Төркиягә барды. Баш министр Төркиягә барганнан соң Адана шәһәрендә республика президенты тарафыннан кабул ителде.

Төркия һәм Англиянең дәүләт эшлеклеләре һәм аларның киңәшчеләре арасында берничә беседа булды. Бу беседаларда Төркия тарафыннан түбәндәгеләр катнашты: министрлар советы председателе Шюкрю Сараджоглы, генеральный штаб начальнигы маршал Фәүзи Чакмак, Чит ил эшләре министры Нуман Менеменджиоглы, Төркиянең хәрби авиациясе командующие Фэридун Эркин, генеральный штабның оператив бүлеге начальнигы полковник Фазик Кайабали; Бөек Британия тарафыннан түбәндәгеләр катнашты: баш министр Уинстон Черчилль, Бөек Британиянең Төркиядәге илчесе Нэчжбелл Хьюгессен, чит ил эшләре министрының даими урынбасары сэр Кадоган, империя генеральный штабы начальнигы генерал Алан Брук, Гыйрак хәрби округы командующие генерал Вильсон, Якын Көнчыгыштагы кораллы көчләрнең командующие генерал Гарольд Александер. Якын Көнчыгыштагы администрация җитәкчесе генерал-лейтенант Линдселл, Якын Көнчыгыштагы хәрби һава көчләре начальнигы урынбасары авиация маршалы Дрэммонд. Урта диңгездәге хәрби операцияләр театрындагы баш командующие штабы начальнигы коммодор Дандэс.

Бу очрашу вакытында чын күңелдән алып барылган беседалар нәтиҗәсендә Төркия белән Берләшкән Корольлек арасында дуслык мөнәсәбәтләре һәм үзара аңлашу расланды һәм тагын да ныгытылды. Төркиянең дәүләт эшлеклеләре соңгы кискен еллар эчендә Төркия тарафыннан алып барылган политикага күзәтү ясадылар, ә баш министр Төркия тарафыннан үткәрелгән политиканы Гали җанап хөкүмәтенең тулысынча симпатия һәм аңлау белән күзәтеп торганлыгына аларны ышандыра алды. Төркиянең һәм Англиянең дәүләт эшлеклеләре Европада яшәп килә торган, бигрәк тә Төркияне турыдан-туры кызыксындырган районнардагы хәлне бергәләшеп карадылар. Барлык төп мәсьәләләр буенча карашларның бер-берсенә туры килгәнлеге билгеләнде.

Төркиянең гомуми куркынычсызлыгын ныгыту өчен Бөек Британия һәм Кушма Штатларның Төркиягә күрсәтә ала торган материаль ярдәмнең характеры турында килешүгә ирешелде. Бу мәсьәләләр буенча Төркиянең һәм Англиянең хәрби киңәшчеләре арасында да сөйләшүләр барды. Күптән түгел генә Кушма Штатлар президенты белән киңәшкән баш министр, президент Рузвельтның тоткан позициясен тулысынча белгән хәлдә, сөйли алды. Президент Рузвельт бу очрашуны оештыру турындагы тәкъдимне кайнар рәвештә котлады. Сугыштан соңгы проблемаларга да әһәмият бирелде һәм алар турында да шулай ук килешүгә ирешелде.

30 нчы һәм 31 нче январьда Адана шәһәрендә үткәрелгән бу сөйләшүләрдән соң, Төркиянең һәм Англиянең дәүләт эшлеклеләре үзләренең тулысынча канәгатьләнгәнлекләрен белдерделәр».

СССР ГА КЫТАЙНЫҢ ЯҢА ИЛЧЕСЕН БИЛГЕЛӘҮ

ЧУНЦИН, 1 февраль. (ТАСС). Кытай хөкүмәте Шао-Ли-Цзе урынына СССР га илче итеп Фу-Пин-Чанны билгеләде. Шао-Ли-Цзе күптән түгел Чунцинга кайтты. Фу-Пин-Чан соңгы вакытка кадәр чит ил эшләре министры урынбасары булып эшләгән иде.

Яңа илченең СССР га китүе уңае белән Кытайның культура оешмалары Кытай—Совет культура җәмгыяте бинасында кабул итү оештырдылар. Кабул итү җыелышында Кытайның дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, шулай ук СССР ның Кытайдагы илчесе иптәш Панюшкин катнашты.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60

ПФ 662 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 205